РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«28» октябрь 2025 ел г. Альметьевск №2588

**Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Җир кишәрлекләрен милеккә түләүсез алу хокукына ия затлар буларак исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 19 ноябрендәге 1641 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законнар, 1998 елның 10 июлендәге 1736 номерлы Татарстан Республикасы Җир кодексы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Җир кишәрлекләрен милеккә түләүсез алу хокукына ия затлар буларак исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 19 ноябрендәге 1641 номерлы карарына (Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 22 июлендәге 1547 номерлы, 2022 елның 28 сентябрендәге 2130 номерлы, 2023 елның 31 мартындагы 751 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карарга 1 нче кушымтада:

1.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.2. Хезмәтне алучылар: физик затлар – үз составында үзара никахта торучы яисә никахта тормаучы, әмма бергә яшәүче ата-анасы (уллыкка алучылар, опекуннар, попечительләр) яисә бер ата-анасы (уллыкка алучы, опекун, попечитель) булган күпбалалы гаилә әгъзалары (алга таба - ата-ана, бер ата-ана), шулай ук өч һәм аннан да күбрәк бала, шул исәптән үги уллары, үги кызлары, уллыкка алынган (кызлыкка алынган) һәм опекага алынган (аларга карата опека һәм попечительлек вакыты чикләнмичә яисә алар балигъ булганчыга кадәр гамәлгә ашырыла), өлкән бала 18 яшькә яисә 23 яшькә җиткәнче, белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмада белем алуы

заказ № 4553-940

шарты белән, гариза бирү датасына укуның көндезге формасында әгәр мондый гражданнар, ата-аналарның берсе булса да яисә бердәнбер ата-ана булса да, җир кишәрлеген милеккә бирү (тапшыру) турында, җир кишәрлеге бирү турында гариза биргән көнгә кадәрге биш ел дәвамында Татарстан Республикасы территориясендә даими яшиләр һәм социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннарына мохтаҗлар буларак исәптә торалар (алга таба - мөрәҗәгать итүче).

Шул ук вакытта күпбалалы гаилә составына никахта тормаучы ата-ана, аларның кимендә өч уртак баласы булган очракта, кертелә. Татарстан Республикасы Җир кодексының 32 статьясындагы 3 пунктында каралган нигезләр буенча җир кишәрлеген милеккә бушлай бирү (тапшыру) хокукын гамәлгә ашырган чит ил гражданнары, гражданлыгы булмаган затлар, шулай ук гражданнар күпбалалы гаилә составына кертелми.

Татарстан Республикасы Җир кодексының 32 статьясындагы 3 пунктының 1 пунктчасында каралган җир кишәрлеге бирү турында гариза бирелгән көнгә кадәрге биш ел дәвамында өч һәм аннан да күбрәк баласы булган гражданнарның Татарстан Республикасы территориясендә даими яшәве турындагы таләп, әгәр ата-аналарның берсе генә булса да яисә бердәнбер ата-ана хәрби хезмәткәр булса, кулланылмый.

Мөрәҗәгать итүчеләрнең мәнфәгатьләрен мөрәҗәгать итүче тарафыннан билгеләнгән тәртиптә вәкаләт бирелгән затлар һәм физик затларның законлы вәкилләре (алга таба – мөрәҗәгать итүче вәкиле) тәкъдим итәргә мөмкин.»;

2.5.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.5.1. Муниципаль хезмәтне алу өчен мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгатьнең категориясенә һәм нигезенә карамастан түбәндәге документларны тапшыра:

1) шәхесне таныклаучы документ (республика порталы аша мөрәҗәгать иткән очракта таләп ителми);

2) мөрәҗәгать итүче вәкиле муниципаль хезмәт күрсәтүне сорап мөрәҗәгать иткән очракта, мөрәҗәгать итүче вәкиленең вәкаләтләрен таныклаучы документ (физик затларның законлы вәкилләре мөрәҗәгать иткән очракта таләп ителми);

3) гариза:

- кәгазь чыганактагы документ рәвешендә (шушы регламентка 4 нче кушымта);

- Республика порталы аша мөрәҗәгать иткәндә регламентның 2.5.4 пункты таләпләре нигезендә имзаланган электрон формада (гаризаның электрон рәвешенә тиешле белешмәләр кертү юлы белән тутырыла);

4) башка ата-ананың паспорты (ата-ана никахта торган йә никахта тормаган, әмма бергә яшәгән очракта);

5) балаларның туу турында таныклыклары, шулай ук ундүрт яшькә җиткән балаларның паспортлары;

6) баланы уллыкка алуны билгеләү турында суд карары (баланың туу турындагы таныклыгында уллыкка алучылар ата-ана буларак язылган очраклардан тыш);

7) опекун яисә попечитель билгеләп кую турында опека һәм попечительлек органы акты (опека яисә Попечительлек билгеләгән очракта);

8) опека яисә попечительлекне гамәлгә ашыру турында шартнамә (опека яисә Попечительлек шартнамә буенча гамәлгә ашырылган очракта);

9) никахлашу турында таныклык (ата-ана никахта торган очракта).

10) мөрәҗәгать итүченең социаль наем шартнамәсе буенча бирелә торган торак урынга мохтаҗ буларак исәптә торуын раслый торган документ;

11) җир кишәрлеген бирү турында гариза биргән көнгә кадәрге биш ел

дәвамында мөрәҗәгать итүченең Татарстан Республикасы территориясендә даими яшәү фактын билгеләү хакында суд карары (гариза бирүче паспортында җир кишәрлеген бирү турында гариза биргән көнгә кадәрге биш ел дәвамында Татарстан Республикасы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлү турында тамга булмаган очракта);

12) «Хәрби хезмәткәрләр статусы турында»1998 елның 27 маендагы 76-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә хәрби хезмәткәр статусын таныклаучы документ (ата-ананың берсе яисә бердәнбер ата-ана хәрби хезмәткәр булган очракта);

13) белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмада 18 яшьтән 23 яшькә кадәрге өлкән баланы көндезге бүлектә укыту фактын раслый торган документ.

Әлеге пунктның 10 пунктчасында күрсәтелгән документ, әгәр мөрәҗәгать итүче аны үз инициативасы белән тапшырмаган булса, җирле үзидарәнең вәкаләтле органы тарафыннан мөстәкыйль рәвештә соратып алына.

Әлеге пунктның 11 пунктчасында күрсәтелгән документ, әгәр мөрәҗәгать итүче «Хәрби хезмәткәрләр статусы турында»1998 елның 27 маендагы 76-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә хәрби хезмәткәр статусына ия булса, тапшырылмый.

2. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары А.Ә. Ямалетдиновка йөкләргә.

Район
Башкарма комитеты җитәкчесе А.М. Каюмов